Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының «Кадрәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Кадрәк торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

17.11.2023 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 елның "17" ноябрендә 10 сәгать 00 минутта уткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны түбәндәгечә раслarга: “2024 елда үзара салым акчаларын кертү өчен «Кадрәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кадрәк авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә, I төркем инвалидлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан тыш, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (хәрби хезмәткәрләрне, мобилизацияләнгән, ирекле киткән) һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатыннарын, балигъ булмаган балаларын) түләүдән азат итү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юллау белән килешәсезме:

1. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту(Кадрәк авылы Ленин, Нарат, Басу, Заречная, Яшьләр урамнары юллары өчен вак таш сатып алу һәм җәю);

2. Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу);

3. Урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка мәйданчыкларны ремонтлау (лампаларны, дроссельләрне, фонарьларны сатып алу һәм урамнарны яктырту өчен материаллар сатып алу);

4. Халыкның күпләп ял итү урыннарын ремонтлау, аларга якын территорияләрне төзекләндерү (тракторны карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, трактор (отвал) өчен өстәмә асылма җиһазлар сатып алу, үләннәр әзерләү өчен бензин чалгычлары сатып алу, куакларны кисү өчен бензопычкы сатып алу);

5

.

Су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу, аны чистарту, транспортировкалау һәм халыкка су бирү (материаллар сатып алу) белән тәэмин итүче су башняларын, скважиналарны һәм башка инженер корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау.

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар жыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

сайлау хокукына ия жыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар жыенында 320 катнашучы, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 181 кеше кертелгән, бу 56,6 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар жыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында 181 катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен жыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар жыены карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кадрәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кадрәк торак пунктында гражданнар жыенын узган дип таныргa, гражданнар жыены нәтиҗәләрен - дөрес дип таныргa.

2. I төркем инвалидларыннан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән яшьтәге гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче затлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгән, ихтыярый затлар) һәм аларның гаилә әгъзаларыннан (ата-аналар, ир белән хатын, балигъ булган балалар), ирегеннән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, 2024 елда Кадрәк авыл җирлеге территориясенең Кадрәк торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.

3. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча жирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1). Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы жирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту(Кадрәк авылы Ленин, Нарат, Басу, Заречная, Яшьләр урамнары юллары өчен вак таш сатып алу һәм җәю);

2. Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу);

3. Урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка мәйданчыкларны ремонтлау (лампаларны, дроссельләрне, фонарьларны сатып алу һөм урамнарны яктырту өчен материаллар сатып алу);

4. Халыкның күпләп ял итү урыннарын ремонтлау, аларга якын территорияләрне төзекләндерү (тракторны карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, трактор (отвал) өчен өстәмә асылма җиһазлар сатып алу, үләннәр әзерләү өчен бензин чалгычлары сатып алу, куакларны кисү өчен бензопычкы сатып алу);

5. Су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу, аны чистарту,

транспортировкалау һәм халыкка су бирү (материаллар сатып алу) белән тәэмин итүче су башняларын, скважиналарны һәм башка инженер корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау.

4. Әлеге карарны мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

Авыл җирлеге башлыгы А.А. Михайлов